**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 4 март

№ 131

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе турында» 2012 ел, 7 август, 674 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 ел, 28 декабрь, ФЗ-442 нчы Федераль законның 15 статьясындагы икенче өлеш нигезләмәсен тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе турында» 2012 ел, 7 август, 674 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе»;

3.4 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы вәкаләтләрен тормышка ашыруга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең

башкарма органнары арасында ведомствоара хезмәттәшлек итү кысаларында җибәрелгән ведомствоара үтенечкә җавап әзерләү һәм җибәрү вакыты мәгълүматлар җибәрүчеләр - ТБХО адресына ведомствоара үтенеч кергән көннән ике эш көне тәшкил итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\131.doc